ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2178-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы булып кече һәм урта эшкуарлык субъектларын булдыру өчен шартлар тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашырганда дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру һәм аларга ярдәм итү өчен тәэмин итүчеләр (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында төзелә, үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра яисә җәлеп ителә торган коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар системасы тора.»;
б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы шулай ук түбәндәгеләрне үз эченә ала:
1) эшкуарлыкны үстерү үзәкләрен һәм агентлыкларын;
2) эшкуарлыкка ярдәм итү буенча дәүләт фондларын һәм муниципаль фондларны;
3) кредитлаштыруга булышу фондларын (гарантия фондларын, поручительлек фондларын);

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен инвестицияләр җәлеп итү фондларын;
5) технопаркларны һәм технопарклар белән идарә итүче оешмаларны;
6) инновация-технология үзәкләрен;
7) бизнес-паркларны һәм бизнес-парклар белән идарә итүче оешмаларны;
8) бизнес-инкубаторларны;
9) һөнәрләр палаталарын һәм үзәкләрен;
10) субподрядка ярдәм итү үзәкләрен,
11) маркетинг һәм уку-эш үзәкләрен;
12) экспортка ярдәм үзәкләрен,
13) лизинг компанияләрен;
14) консультация үзәкләрен;
15) индустрия (сәнәгать) паркларын һәм индустрия (сәнәгать) парклары белән идарә итүче компанияләрне;
16) сәнәгать технопаркларын һәм сәнәгать технопарклары белән идарә итүче компанияләрне;
17) технологияләрне коммерциальләштерү үзәкләрен;
18) югары технологияле җайланмалардан күмәк файдалану үзәкләрен;
19) инжиниринг үзәкләрен;
20) прототиплаштыру һәм сәнәгать дизайны үзәкләрен;
21) технологияләрне трансферлау үзәкләрен;
22) кластер үсеше үзәкләрен;
23) эшчәнлекләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра торган фәнни, фәнни-техник, инновация эшчәнлеге үзәкләренә ярдәм итүче дәүләт фондларын;
24) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга микрозаемнар бирүче микрофинанс оешмаларын;
25) социаль өлкә инновацияләре үзәкләрен;
26) сертификацияләү, стандартлаштыру һәм сынау үзәкләрен;
27) халык сәнгать һөнәрләренә ярдәм итү үзәкләрен;
28) авыл һәм экология туризмын үстерү үзәкләрен;
29) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хезмәт күрсәтүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрен;
30) сәүдә-сәнәгать палаталарын;
31) авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләрен;
32) финанс агентлыкларын;
33) кооперативларны;
34) хокук үзәкләрен;
35) махсуслаштырылган җитештерү территорияләрен (җитештерү-технология зоналарын);
36) бизнес-кунакханәләрне;
37) фәнни-тикшеренү оешмаларын;
38) технополислар белән идарә итүче оешмаларны;

39) фәнни паркларны һәм фәнни парклар белән идарә итүче оешмаларны;

40) агросәнәгать паркларын һәм агросәнәгать парклары белән идарә итүче оешмаларны;

41) бүтән оешмаларны.»;

2) 18 статьяның 5 пунктында «технопарклар,» сүзеннән соң «бизнес-парклар,» сүзен өстәргә;

3) 21 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләрен булдыру һәм мондый үзәкләр эшчәнлеген тәэмин итү;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

2023 елның 28 июленнән үз көченә кергән «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 291-ФЗ номерлы Федераль закон белән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар исемлеге, аңа бизнес-паркларны һәм авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләрен кертү юлы белән, үзгәртелде.

Бер үк вакытта кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү төрләренә күрсәтелгән оешмаларны булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү мөмкинлеге дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан өстәлде.

Шулай ук кертелгән үзгәрешләр нигезендә индустрия (сәнәгать) парклары төшенчәсе «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерелде.

Закон проекты белән югарыда күрсәтелгән федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.